Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Каргалы авыл җирлеге Советы

2021 елның 26 октябре №15/5

КАРАР

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 16 августындагы 11/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 16 августындагы 11/2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

12 пунктта «муниципаль вазыйфа яисә» сүзләрен төшереп калдырырга;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Муниципаль хезмәткә яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр кергәндә яисә белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырганда граждан күрсәтелгән гражданны муниципаль хезмәткә кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Муниципаль хезмәткә яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр кергәндә яисә белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырганда граждан күрсәтелгән гражданны муниципаль хезмәткә кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында яисә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

Каргалы авыл җирлеге<br>
башлыгы М.А. Заһидуллин